

Мордовия Республикасы буенча ОСФР (Центра общения ОСФР по Республике Мордовия) аралашу vзәге активистлары экскурсия белән искиткеч урында – Дубенка районы Ломаты авылы музеенда булдылар. Үткән ай башында шулай ук Чамзанкада яшәvче Ломатлылар да туган авыллары музеена килгән иделәр.
Дубенка районынын Ломаты татар авылы кызыклы һәм vзенчәлекле: мордва-әрзәләр һәм руслар белән янәшә яшәп, халык vзенен милли йолаларын һәм ин моһиме – телен саклап калган.
Ветераннар оешмасы рәисе Венера Сәлахетдин кызы Алеева, Ломат музее житәкчесе Мязидә Якуб кызы Муракаева белән, туган авыллары кунакларын бик жылы каршы алдылар. Экскурсия башында Мязидә Якуб кызы диварда урнаштырылган мәгълумат белән таныштырды: фотоларын кvрсәтеп туган авыллары һәм Боек Ватан сугышында катнашучы авылдашлары турында сойләде.



Сугыштан кайткач, аларнын кvбесе колхозда, мәктәптә эшләгәннәр, vзләренен кечкенә Ватанын тергезгәннәр. Аннары музейда сакланган барлык экспонатлар турында жентекләп экскурсантларга ишеттерде: эш кораллары, орләгеч-прялка, солдат фляжкасы, чистарту тактасы, конкvреш әйберләре, милли киемнәр, татар орнаменты белән чигелгән солгеләр, шулай ук борынгы кулъязма китаплар һәм башкалар, һәм башкалар... Кунаклар татар халкы тормышы, конкvреше, дине турында Мәзидә Якуб кызы хикәясеннән кvп кызыклы нәрсәләр белделәр һәм хәтта ялан аяк, милли киемнәр киеп, яшел vләндә йорделәр.
Сvз унаеннан, экскурсиягә килгән олылар белән оныклары да килгән иде. Алар очен бу экскурсия татар халкынын гореф-гадәтләрен яхшырак белергә ярдәм итте. Ә соныннан, чын татар кунакчыллыгы нәрсә икәнен белде кунаклар: экскурсия тәмамланганнан сон хуш исле vлән чәе, тәмле татар пәрәмәчләре, «колаклары», тәм-томнар белән сыйландылар! Чәй эчкәннән сон, барлык катнашучылар бергә фотога тоштеләр. Бу онытылмаслык чара очен Мязидә Якубовна һәм Венера Сәлахетдиновнага зур рәхмәт әйтеп, зур унай эмоцияләр белән таралыштылар экскурсиядә булганнар.

**Наилә НАСЫРОВА**